КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1354

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче; 2015 ел, 3 июль, 483 нче; 2015 ел, 22 август, 612 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1033 нче; 2016 ел, 9 март, 132 нче; 2016 ел, 13 май, 306 нчы; 2016 ел, 7 июль, 462 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2017 ел, 7 август, 562 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 13 июнь, 490 нчы; 2019 ел, 2 сентябрь, 749 нчы; 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче; 2021 ел, 15 февраль, 80 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе» (алга таба – ТР ДТИ);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» (алга таба – ТР Цифрлаштыру министрлыгы).»;

6 пункт таблицасында:

8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «8. | ИИК, ТРХКО, ИХҮ | Исәп-хисап һәм мәгълүматларны тапшыру:<br>фактта күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр, антенна хезмәтләре, шәхси счетлар яктылыгында коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары өчен исәпләүләр турында;<br>ике ай эчендә торак урын һәм (яки) коммуналь хезмәтләр өчен агымдагы түләүләрне түләмәү турында;<br>гражданнар белән бурычларны каплау буенча килешүләр төзү һәм (яки) гражданнар тарафыннан аларның үтәлүе турында;<br>коммуналь хезмәтләрне сүндерү факты турында;<br>коммуналь хезмәтләрне тоташтыру факты турында;<br>торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саны турында; | электрон | хисап аеннан соң килә торган айның 3 енә кадәр | МЯРҮ бүлекләре»; |

түбәндәге эчтәлекле 31 – 32 пунктчалар өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «31. | ИИК, ТРХКО | Торак-коммуналь хуҗалык буенча дәүләт мәгълүмат системасыннан ведомствоара сорату юлы белән торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен соңгы өч елдан артмаган чорга барлыкка килгән, түләнмәгән, закон көченә кергән суд акты белән расланган бурычларның булуы яки булмавы турында мәгълүматлар алу | электрон | сорату алган көннән 5 эш көне эчендә | МЯРҮ бүлекләре |
| 32. | ТР Цифрлаштыру министрлыгы | Торак-коммуналь хуҗалык буенча дәүләт мәгълүмат системасыннан торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен соңгы өч елдан артмаган чорга барлыкка килгән, түләнмәгән, закон көченә кергән суд акты белән расланган бурычларның булуы яки булмавы турында мәгълүматлар кермәгән адреслар реестры | электрон | хисап аеннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр | ТР ДТИ». |

2. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин